РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КАРАМАЛИНСКИЙ СОВЕТ
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Центральная, д 8, с.Карамалы,
Азнакаевский муниципальный район
423301

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАРАМАЛЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕК СОВЕТЫ

Үзәк ур., 8 нче йорт, Карамалы авылы,
Азнакай муниципаль районы, 423301

Тел./факс(885592)4-56-42; E-mail:Karam.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» ноябрь 2019 ел №52

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджет проекты турында фикер алышуда катнашу өчен ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10. 2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының 19.04.2012 ел № 34 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына

бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Халык алдында тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2019 елның 03декабре 16 сәгатьтә;

- үткәрү урыны-Карамалы авыл мәдәният йорты;

- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес: Карамалы авылы, Үзәк урам,8 йорт.

4. Гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең норматив хокукый актлары һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең мәгълүмәт стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмәт рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча 2019 елның 14 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык А.Р. Ногманов

КАРАМАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАМАЛИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

**ПРОЕКТ**

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**

**Карамалы авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

Карамалы авылы №__ « __ » декабрь 2019 ел

**2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджеты турында**

**Статья 1**

1. 2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 6 476,1 мең сумм итеп;

2) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 6 476,1 мең сумм итеп;

3) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0,0 мең сум итеп.

2. 2021 елга һәм 2022 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2021 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 6 478,5 мең сум һәм 2022 елга 6 481,9 мең сум итеп;

2) 2021 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 6 478,5 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарын 159,7 мең сум итеп һәм 2022 елга 6 481,9 мең сум шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарын 319,5 мең сум итеп;

3) 2021 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0,0 мең сум һәм 2022 елга 0,0 мең сум итеп.

3. 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге Карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

**Статья 2**

1. 2021 елның 1 гыйнварына  расларга:

1) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының иң югары чиге 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча эчке бурычының иң югары чиге Россия Федерациясе валютасында нуль күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең муниципаль тышкы бурычының югары чиге нуль күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча тышкы бурычының иң югары чиге-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең чит ил валютасында муниципаль гарантияләр буенча нульгә тигез.

2. 2022 елның 1 гыйнварына расларга:

1) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының иң югары чиге 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча эчке бурычының иң югары чиге Россия Федерациясе валютасында нуль күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең муниципаль тышкы бурычының югары чиге нуль күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча тышкы бурычының иң югары чиге-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең чит ил валютасында муниципаль гарантияләр буенча нульгә тигез.

3. 2023 елның 1 гыйнварына расларга:

1) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының иң югары чиге 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча эчке бурычының иң югары чиге Россия Федерациясе валютасында нуль күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең муниципаль тышкы бурычының югары чиге нуль күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча тышкы бурычының иң югары чиге-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең чит ил валютасында муниципаль гарантияләр буенча нульгә тигез.

4, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге муниципаль гарантияләрен үтәүгә каралган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге

бюджетының бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен, 2020 елга 0,0 мең сум, 2021 елга 0,0 мең сум, 2022 елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

**Статья 3**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджетында 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

**Статья 4**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге Карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге Карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

**Статья 5**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә 2020 елга 68,5 мең сум күләмендә, 2021 елга 150,2 мең сум күләмендә, 2022 елга 151,9 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен расларга.

2. 2020 елда, 2021 һәм 2022 еллар план чорында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара субсидияләрне ай саен тигез өлеш белән күчерү гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә җирле бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле субсидия күләме, бер кешегә исәпләгәндә, аерым муниципаль берәмлек өчен хисап финанс елында җирле бюджетның бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәре (түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәрен исәпкә алмыйча) һәм бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәренең 1,3 тапкыр арттырылган уртача дәрәҗәсе арасындагы аерманың 2021 елда 3 процентын, 2020 елда - 7 процентын, 2022 елда - 7 процентын тәшкил итә дип билгеләргә.

**Статья 6**

1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.5 статьясы нигезендә, җирлек халыкны мәдәният учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар булдыруга, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен төзелгән килешүләр

нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетына күчерелергә башка бюджетара трансфертлар күләмен 2020 елга 2 773,2 мең сум, 2021 елга 2 780,8 мең сум, 2022 елга 2 788,7 мең сум күләмендә расларга.

2. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслауга муниципаль учреждениеләрне тоту буенча төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетына тапшырыла торган субсидияләр күләмен, 2020 елга 1 931,0 мең сум, 2021 елга 1 832,8 мең сум, 2022 елга 1 809,6 мең сум күләмендә расларга.

3. 2020 елда һәм 2021, 2022 еллар план чорында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетына әлеге статьяда каралган субсидияләр, башка бюджетара трансфертлар ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә.

**Статья 7**

1. 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасының Азнакай муниципаль районы программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Карарның 6 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3. 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Татарстан Республикасының Азнакай муниципаль районы программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге Карарның 7 нче кушымтасы нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджет ассигнованиеләренең гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган гомуми күләмен 2020 елга 0,0 мең сум, 2021 елга 0,0 мең сум һәм 2022 елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

**Статья 8**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджетында 2020 елга Азнакай муниципаль районы бюджетыннан алына торган хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләр күләмен 92,1 мең сум күләмендә, 2021 елга 92,2 мең сум күләмендә, 2022 елга 93,6 мең сум күләмендә исәпкә алырга кирәк.

**Статья 9**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге үзидарә органнары 2020 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

**Статья 10**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**Статья 11**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджетының 2020 елның 1 гыйнварына калган акчалары Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактларның шартлары нигезендә товарлар белән тәэмин итү, эшләр башкару, 2019 елда түләнергә тиешле хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар суммасыннан артмаган күләмдә, 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**Статья 12**

Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

**Статья 13**

Әлеге Карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Статья 14**

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис А.Р. Ногманов